**СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423190, с. Новошешминск, ул. Советская, 80
тел.: (84348) 2-31-00, факс: (8-4348) 2-20-22

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ**

423190,Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80
тел.: (8-4348) 2-31-00, факс: (84348) 2-20-22

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2025 елның «29» декабреннән

№ 5-29

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 91, 92 һәм 93 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 16 октябрендәге 2-9 номерлы; 2016 елның 11 февралендәге 9-32 номерлы; 2016 елның 28 сентябрендәге 18-82 номерлы; 2016 елның 14 декабрендәге 20-103 номерлы; 2017 елның 17 апрелендәге 25-132 номерлы; № 17.08.2017 елның 17 августындагы 28-150 номерлы; 2017 елның 14 декабрендәге 31-180 номерлы; №, 25.05.2018 елның 25 маендагы 37-209 номерлы; 2018 елның 13 декабрендәге 43-252 номерлы; 2019 елның 05 июлендәге 50-299 номерлы; 2020 елның 04 июнендәге 61-378 номерлы; 2021 елның 02 июнендәге 10-70 номерлы; 2021 елның 09 декабрендәге 16-124 номерлы; 2022 елның 07 июлендәге 24-181 номерлы; 2023 елның 16 мартындагы 32-245 номерлы; 2024 елның 27 мартындагы 43-332 номерлы, 2024 елның 13 декабрендәге 50-387 номерлы, 2025 елның 5 июнендәге 57-434 номерлы карарлары редакциясендә) (алга таба – Устав) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Уставның 33 статьясын түбәндәге эчтәлекле пункт белән тулыландырырга:

«33) Башкарма комитет җитәкчесе урынбасарларын, Башкарма комитетның тармак (функциональ) органнары җитәкчеләрен вазыйфаларына билгеләп куюларны килештерә;»;

1.2. Уставның 49 статьясындагы 4 пунктында «(икътисад буенча)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 52 статьяның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы белән килештереп, район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарларын, башкарма комитетның тармак (функциональ) органнары җитәкчеләрен вазыйфаларына билгеләп куя һәм вазыйфаларыннан азат итә, алар арасында вазыйфалар бүлә, муниципаль хезмәткәрләрне һәм Башкарма комитетның башка хезмәткәрләрен вазыйфаларына билгели һәм вазыйфаларыннан азат итә, аларның эшчәнлеген тикшереп тора, аларга карата кызыксындыру һәм дисциплинар җаваплылык чараларын куллана;».

2. Әлеге карарны законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт тарафыннан теркәү уздыру өчен юлларга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында дәүләт теркәве узганнан соң «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендә: http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http// novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләнә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы Е.А. Тарнавский